**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об отмене ограничительных мероприятий (карантина), установленных на отдельной территории Тюлячинского района Республики Татарстан в связи с ее неблагополучием по заболеванию высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения

В связи с выполнением противоэпизоотических и профилактических мероприятий по ликвидации и предотвращению заболевания высокопатогенным гриппом птиц, в соответствии со статьей $3^1$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии», приказом Министерства сельского хозяйства Российской Федерации от 27 марта 2006 года № 90 **постановляю**:

1. Отменить ограничительные мероприятия (карантин), установленные в связи с неблагополучием по заболеванию высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения на территории частного подворья дома № 17 по улице Державина в поселке Петровский Тюлячинского района Республики Татарстан.

2. Ограничить на территории, указанной в пункте 1 настоящего Указа, в течение трех месяцев для всех владельцев птиц вывоз инкубационного яйца и живой птицы всех видов и возрастов в другие хозяйства.

3. Признать утратившим силу Указ Президента Республики Татарстан от 7 июня 2017 года № УП-479 «Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на отдельной территории Тюлячинского района Республики Татарстан в связи с ее неблагополучием по заболеванию высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения».

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
01 июля 2017 года
№ УП-595

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Теләче районының аерым территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлегә сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында

Кошларның йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләвен бетерү һәм булдырмауга юнәлтелгән эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар үтәлүгә бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2006 елның 27 мартындагы 90 номерлы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Теләче районы Петровский поселогының Державин урамындагы 17 номерлы шәхси хуҗалык территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлегә сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территориядә өч ай дәвамында барлык кош-корт асраучыларга башка хуҗалыкларга яралгылы йомырка һәм барлык төрдәге тере кош-корт чыгаруны чикләргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Теләче районының аерым территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлегә сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2017 елның 7 июнендәге ПУ-479 номерлы Указын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Минниханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 01 июль
№ ПУ-595